КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 12 февраль г.Казань № 75

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы ведомствосындагы дәүләт бюджет учреждениеләренә дәүләт эшләрен башкаруга норматив чыгымнарны билгеләү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы аларга карата гамәлгә куючы вазыйфаларын һәм вәкаләтләрен башкарган дәүләт бюджет учреждениеләренә дәүләт эшләрен башкаруга норматив чыгымнарны билгеләү тәртибен расларга.

2. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгына, «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә ел саен Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы аларга карата гамәлгә куючы вазыйфаларын һәм вәкаләтләрен башкарган дәүләт бюджет учреждениеләренә дәүләт эшләрен башкаруга норматив чыгымнарны әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән Тәртип нигезендә исәпләүне гамәлгә ашырырга.

3. Дәүләт эшләрен башкаруга норматив чыгымнарны исәпләү елга бер тапкыр чираттагы финанс елына Татарстан Республикасы бюджеты проектын формалаштырганда гамәлгә ашырыла.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин